**Татарстан Республикасы Азнакай районы Советы**
**дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 271-32 «28» март 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай районы Советының 2022 елның 25 февралендәге 120-15 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында»гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (12.10.2022 №176-19, 18.04.2023 №218-24, 23.08.2023 №238-26, 25.10.2023 №243-27 карарлар редакциясендә)

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 2023 елның 28 сентябрендәге 86-ТРЗ номерлы Законы нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай районы Советының 2022 елның 25 февралендәге 120-15 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында»гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (12.10.2022 №176-19, 18.04.2023 №218-24, 23.08.2023 №238-26, 25.10.2023 №243-27 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 пунктның 8.1 бүлегендә түбәндәге эчтәлекле 12 пунктчаны өстәргә:

«12) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) шушы Нигезләмәнең 14.1 бүлегендә каралган анкетадагы белешмәләрнең мәгълүм үзгәрешләр турында язма рәвештә хәбәр итәргә, моңа яллаучы (эш бирүче) вәкиленең карары буенча үзгәргән белешмәләр керми (алга таба - анкетадагы белешмәләр).».

1.2. 9 пунктның 8 пунктчасын 9.1. бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны узу чорында ялган документлар һәм (яисә) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрнең, тыюларның һәм таләпләрнең үтәлүен раслый торган, яисә документларны һәм (яисә) белешмәләрне тапшырмаганда, аларны бозган өчен муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү турында таныклый торган тәкъдимнәр;».

1.3. түбәндәге эчтәлектәге 15.1 бүлекне өстәргә:

«15.1. анкета тапшыру, анкетадагы белешмәләрне үзгәртү турында хәбәр итү һәм мондый белешмәләрне тикшерү

15.1.1. Граждан муниципаль хезмәткә кергәндә анкета бирә.

15.1.2. Муниципаль хезмәткәр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) анкетада булган белешмәләрнең үзенә мәгълүм булган үзгәрешләр турында язма рәвештә хәбәр итә.

15.1.3.Анкетаның формасы, шул исәптән аңа кертелә торган белешмәләр исемлеге, аларны актуальләштерү тәртибе һәм сроклары Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнә.

15.1.4. Анкеттагы белешмәләр яллаучының (эш бирүченең) яисә ул вәкаләт биргән затның карары буенча тикшерелергә мөмкин. Анкетадагы белешмәләрне

тикшерү гавами хакимият органнарына һәм тиешле мәгълүматка ия оешмаларга, язма рәвештә, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары ярдәмендә, җибәрү юлы белән муниципаль органның кадрлар хезмәте тарафыннан гамәлгә ашырыла. Тиешле мәгълүматка ия гавами хакимият органнары һәм оешмалар соратып алына торган мәгълүматны соратып алынган гаризаны алган көннән бер айдан да соңга калмыйча бирергә тиеш.».

1.4 16 бүлектә:

- 16.3 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкета;

- 16.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16.4. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон нигезендә граждан тарафыннан муниципаль хезмәткә кергәндә тапшырылган белешмәләр (анкетадагы белешмәләрдән тыш) федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерелергә мөмкин.».

1.5. 27 бүлекнең 27.1 пунктының:

- 11) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм муниципаль хезмәткәрләргә узган вакытта граждан тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне тикшерүне оештыру һәм үткәрү;».

- түбәндәге эчтәлекле 11.1 пунктчаны өстәргә:

«дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларга билгеләнгән формага рөхсәт бирүне рәсмиләштерү;».

2. Әлеге карарны түбәндәге веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo. tatarstan.ru һәм “Интернет” мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин